ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 15 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 өлешендә:
а) 9 пунктта «оештыру» сүзеннән соң «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү» сүзләрен өстәргә;
б) 28 пунктта «гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү, гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп» сүзләрен «гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан

гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп, гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен, шулай ук су объектларыннан рекреация максатлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

2) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 11 пунктта «оештыру» сүзеннән соң «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле шәһәр округы территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү» сүзләрен өстәргә;

б) 36 пунктта «гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү һәм мондый су объектларыннан файдаланудагы чикләүләр турында халыкка мәгълүмат бирү, гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп» сүзләрен «гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп, гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү һәм мондый су объектларыннан файдаланудагы чикләүләр турында халыкка мәгълүмат бирү, шулай ук су объектларыннан рекреация максатлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

3) $49^1$ статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында каралган халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында мөрәҗәгать җибәрә.

Җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 – 5 пунктларында каралган халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында мөрәҗәгать җибәрә.»;

б) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Әлеге статьяның 3 өлешендәге беренче абзацында каралган очракта халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында җирле үзидарә органының мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау нәтиҗәләре халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара

электрон документлар әйләнеше системасы аша әлеге мөрәҗәгатьне җибәргән җирле үзидарә органына җиткерелә.

Әлеге статьяның 3 өлешендәге икенче абзацында каралган очракта халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында җирле үзидарә органының мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау нәтиҗәләре халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша әлеге мөрәҗәгатьне җибәргән җирле үзидарә органына җиткерелә.»;

4) $49^2$ статьяның 1 өлешендә «Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыру турындагы килешү» сүзләреннән соң «(төп нөсхәсе)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасыннан һәм 2 пунктының «а» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасы һәм 2 пунктының «а» пунктчасы 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 01 март
№ 9-ТРЗ